**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы**
**_Катмыш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге**
**гражданнар җыены карары**

23» ноябрь 2019 ел. № 1

**Мамадыш муниципаль районы**
**Катмыш авыл җирлеге составына керүче**
**Еники Чишмә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принципларры турында»гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче маддәләре, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 ст., Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең Еники Чишмә авылында 2019 елның 23 нче ноябрендә узган үзара салым акчаларын куллану һәм кертү буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Еники Чишмә авылы торак пуктында Совет урамына юлга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эшләр өчен түләү);
-Еники Чишмә авылы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
- Еники Чишмә авылы торак пунктында елга янында янгын техникасы беләнсу алу өчен пирс булдыру ( сатып алу, ташу, таш җәю, килешү буенча түләү);
- Еники Чишмә торак пунктында энергия саклаучы лампаларны техник карау һәм урнаштыру.

« ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 87 кеше кертелгән;

халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 49 кеше;

Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» 47 кеше тавыш бирде;

«Юк» 2 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең Еники Чишмә авылында узган халык җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең Еники Чишмә авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Еники Чишмә авылы торак пуктында Совет урамына юлга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эшләр өчен түләү);

-Еники Чишмә авылы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

- Еники Чишмә авылы торак пунктында елга янында янгын техникасы белән су алу өчен пирс булдыру ( сатып алу, ташу, таш җәю, килешү буенча түләү);

- Еники Чишмә торак пунктында энергия саклаучы лампаларны техник карау һәм урнаштыру.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге
Советы рәисе И.Г.Габидуллин